Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет майданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Арча шәһәр Советы

карары

« 9 » август 2016 ел № 37

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урамга исем бирү турында**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 07.12.2005 ел, № 116-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Арча шәһәре Советының 18.12.2015 ел, № 15 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең топонимика комиссиясе турында" карары нигезендә, тарихи шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү максатларында, татар мәдәниятенә зур өлеш керткән өчен, Арча шәһәре Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең яңа урамына түбәндәге исемне бирергә:

- "Бакый Урманче»;

2. Арча шәһәре Башкарма комитетына бер ай вакыт эчендә йөкләргә:

- «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге урамнары исемнәре реестрына яңа төзелгән урам исемен кертергә;

- яңа урамда адреслы атрибутика урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

«Совет города Арск»

И.Г. Нуриев